КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 июнь г.Казань № 665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2015 ел, 29 апрель, 299 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 671 нче; 2016 ел, 23 июнь, 429 нчы; 2016 ел, 23 сентябрь, 682 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 1000 нче; 2017 ел, 7 февраль, 62 нче; 2017 ел, 15 февраль, 88 нче; 2017 ел, 8 июнь, 362 нче; 2017 ел, 26 июнь, 436 нчы; 2017 ел, 22 декабрь, 1028 нче; 2017 ел, 25 декабрь, 1030 нчы; 2018 ел, 21 май, 383 нче; 2018 ел, 24 сентябрь, 842 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1182 нче; 2019 ел, 8 апрель, 275 нче; 2019 ел, 3 июнь, 464 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 854 нче; 2020 ел, 27 гыйнвар, 24 нче; 2020 ел, 28 май, 437 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1086 нчы; 2021 ел, 30 июль, 666 нчы; 2022 ел, 19 май, 464 нче; 2022 ел, 20 июль, 699 нчы; 2022 ел, 6 сентябрь, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның 1 нче кушымтасындагы «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү» юлында:

«Үтәү срогы куелган йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән контроль срокларда башкарылган югары оешмалар йөкләмәләре өлеше, %» өстәмә юлының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары тарафыннан үтәү өчен контроль срогы билгеләнгән йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда үтәлгән әлеге затларның йөкләмәләре өлеше, %»;

«Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан башкарылган шәхсиләштерелгән йөкләмәләр өлеше, %» өстәмә юлының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан башкарылган шәхсиләштерелгән йөкләмәләр, шул исәптән «Ачык Татарстан» системасында үз вакытында яңартылган хисаплар өлеше, %»;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы паспортыннан соң егерме беренче һәм егерме икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары тарафыннан үтәү өчен контроль срогы билгеләнгән йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда үтәлгән әлеге затларның йөкләмәләре өлеше, процент;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан башкарылган шәхсиләштерелгән йөкләмәләр, шул исәптән «Ачык Татарстан» системасында үз вакытында яңартылган хисаплар өлеше, процент;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин